СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.03.2025 г. Агрыз № 45-6

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен төзү турында” 22.10.2020 елның 2-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында” 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнарындагы кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен төзү турында” 22.10.2020 ел, 2-2 номерлы карарына кушымта итеп бирелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарны «Татмедиа» АҖ филиалының “Әгерҗе хәбәрләре” (“Агрызские вести”) Әгерҗе районы газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru), “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советының 11.03.2025 елның 45-6 номерлы
карары белән расланды
(11.07.2024 № 38-4 карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясен төзү турында” 22.10.2020 елның 2-2 номерлы карарына үзгәрешләр:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составыннан комиссия әгъзаларын чыгарырга:

- Сутягина А.Р., Ерохина Н.В., Затулина Н.С., Петряева Е.А.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына кертергә:

- Бадахшин Равил Нәвит улы – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – комиссия рәисе;

- Обухова Ксения Александровна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторының баш белгече;

- Фәрхетдинова Азалия Рөстәм кызы - Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлекнең балигъ булмаганнар эшләре инспекторы (килешү буенча);

- Закирова Эльвира Марат кызы – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының социаль үсеш бүлеге җитәкчесе.